СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

31.01.2022 с. Верхний Услон № 19-263

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы Советы

карар итте:

1. «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына Иннополис шәһәре Башкарма комитетының түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

- җирлек чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм алардан килгән зыяннарны бетерү эшендә катнашу;

- территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, җирлек халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

- су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, аларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру;

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына Иннополис шәһәре Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштыру.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиатдинов